ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.05.2022 ел Баулы шәһәре №97

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2022 елның икенче кварталына Баулы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясенең нормативын билгеләү турында

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 мартындагы 888 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы 215/пр номерлы «Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2022 елның 29 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның Эксперт-консультация советының 2022 елның II кварталына торак урыннарның бер квадрат метрының уртача бәясен билгеләү буенча тикшеренүләренә таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елның икенче кварталына яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Баулы муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясенең нормативын 28 917 (егерме сигез мең тугыз йөз унҗиде) сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинага йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров